Татарстан Республикасы
Кукмара муниципаль районы
Сәрдекбаш авыл җирлеге Советы

КАРАР

20 ноябрь 2020 ел № 11

«Җир салымы турында» Сәрдекбаш авыл җирлеге Советының 2013 елның 22 ноябрендәге 29 номерлы карарының 4 пункты үз көчен югалткан дип тану хакында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 29 сентябрендәге 325-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Сәрдекбаш авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. «Җир салымы турында» Сәрдекбаш авыл җирлеге Советының 2013 елның ноябрендәге 29 номерлы карарының 4 пункты (Сәрдекбаш авыл җирлеге Советының 2014 елның 24 ноябрендәге 33 номерлы, 2015 елның 28 маендагы 24 номерлы, 2015 елның 24 ноябрендәге 10 номерлы, 2017 елның 27 июнендәге 10 номерлы, 2018 елның 7 ноябрендәге 31 номерлы, 2018 елның 29 ноябрендәге 35 номерлы, 2018 елның 20 декабрендәге 38 номерлы, 2019 елның 28 ноябрендәге 23 номерлы, 2020 елның 28 гыйнварындагы 4 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча, шулай ук Сәрдекбаш авыл җирлеге торак пунктлары территориясендә махсус мәгълүмати стендларда урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан, әмма рәсми басылып чыккан көннән кимендә бер айдан соң үз көченә керә.

Сәрдекбаш авыл җирлеге башлыгы: И.М.Нәбиев